Таныштым
Озот

# Актаныш муниципаль районында 2019 елга гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре турында мәгълүмат

Безнең төп тырышлыгыбыз - 2019 елда район Советы һәм Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты структур бүлекчәләрендә документлар белән эшләүне оештыру һәм координацияләү мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелде. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре төрле каналлар буенча: гади һәм электрон почта, мөрәҗәгать итүчеләрне турыдан-туры китерү, гражданнар белән шәхси кабул итүләрдә, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, хуҗалыкларда булганда турыдан-туры аралашу юлы белән керә. Мәгълүматтан файдалану хокукын һәм мондый мөмкинлекне бирү бурычын гамәлгә ашырып, район Советы һәм Башкарма комитеты гражданнарны IT технологияләр кулланып мәгълүмати тәэмин итү челтәрен үстерүгә зур игътибар бирәләр. Районның рәсми сайтында Совет һәм Башкарма комитет җитәкчеләре, структур бүлекчәләр турында мәгълүмат урнаштырылган.

Мәгълүмати технологияләрне куллану кирәклеген исәпкә алып, 2010 елдан Актаныш муниципаль районы Советында, Башкарма комитетында электрон документ әйләнеше системасын тулы масштаблы гамәлгә кертү булды. Бу карарлар кабул итүнең тизлеген, аларның сыйфатын арттырырга, эш барышының үтә күренмәлелегенә ирешергә, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга мөмкинлек бирде. Гомуми бүлек белгечләре тарафыннан, мәгълүматлаштыру бүлеге белгечләре белән берлектә, әлеге программаны эшләтеп җибәрү чорында зур эш башкарылды (керүче һәм чыгучы документларны үтү схемалары төзелде, хисаплар системасы эшләнде, Совет, Башкарма комитет белгечләрен, шулай ук авыл җирлекләре башлыкларын укыту үткәрелде).

Электрон документ әйләнеше системасын кертү белән бер үк вакытта документларны килештерү процессларын оптимальләштерү дә башкарылды. Мөмкин булганча документлар узу чылбырлары максималь кыскартылды.

Актаныш муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2003 елның 11 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнарның һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 03.12.2007 ел, нигезендә уздырыла.

2019 нчы ел дәвамында муниципаль район Башлыгы һәм Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына гражданнардан 256 мөрәҗәгать керде, шулардан 38 мөрәҗәгать интернет аша кабул ителде.

Гражданнарның мөрәҗәгатьләре буенча 37 күрсәтмә югарыдагы органнар аша бирелде. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, мөрәҗәгать итүчеләрнең югары органнарга мөрәҗәгатьләренең күпчелеге Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол калган хатыннарының, локаль сугышларда катнашучыларның, дәүләт торак

программаларында катнашу хокукына ия яки әлеге программалар буенча финанс йөкләмәләрен көчәйтә алмый торган ташламалы категория гражданнарның торак мәсьәләсен хәл итү белән бәйле.

Муниципаль район Башлыгы һәм Башкарма комитет җитәкчесе адресына гражданнарның мөрәҗәгатьләре тематикасы, нигездә, халыкның социаль һәм икътисади хәленә кагылышлы мәсьәләләр белән тәкъдим ителә: торак шартларын яхшырту (36,3%), коммуналь-көнкүреш хезмәте күрсәтү (5%), эшкә урнашу, халыкны социаль яклау (10,9%), җирдән файдалану (3,5%) мәсьәләләре.

| | | |
|---|---|---|
| Төзелеш, архитектура һәм торак шартларын яхшырту | 93 | 36,3% |
| Җир буенча сораулар | 9 | 3,5% |
| Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау | 28 | 10,9% |
| Мәгариф, фән, мәдәният, спорт | 53 | 20,7% |
| Икътисад, сәнәгать | 10 | 3,9% |
| Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек | 6 | 2,3% |
| Торак-коммуналь хуҗалык | 13 | 5% |
| Сәламәтлек саклау | 8 | 3,1% |

Халыкны социаль яклау Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлегенең мөһим аспекты булып тора. Социаль яклау учреждениеләренең эше һәр конкрет кешегә максималь якын, аның проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән. 2019 елда Актаныш муниципаль районы Советына һәм Башкарма комитетына эшкә урнашу, ташламалар бирү проблемалары белән бәйле 28 мөрәҗәгать керде. Соңгы еллар дәвамында әлеге мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләр саны даими булып кала бирә. Район оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләренең игътибарын халыкның төрле категорияләрендәге социаль проблемаларына җәлеп итү, шефлык элемтәләрен урнаштыру һәм күп кенә мәсьәләләрне хәл итү максатыннан, «Әниләр көне», «Өлкәннәр көне», «Шәфкатьлелек марафоны» кебек чаралар үткәрү дә ярдәм итә.

Халык өчен уңайлы вакытта гражданнарны кабул итү графигы расланды. Муниципаль район Башлыгы, аның урынбасары, Башкарма комитет җитәкчесе, аның урынбасарлары, структур бүлекчәләр башлыклары гражданнарны шәхсән кабул итәләр. Бердәм кабул итү көне – сишәмбе саклана. Кирәкле документлар (шәхси кабул итү карточкалары яки кайбер бүлекчәләрдә журналлар) законнар нигезендә рәсмиләштерелә. Бүлекчә җитәкчеләре урынбасарлары кабул итүне пәнҗешәмбе көннәрендә генә түгел, кирәк булганда алдан язылмыйча да алып баралар. Гражданнарга, куелган сораулары буенча, кабул ителгән карар турында хәбәр ителә яки аңлатма бирелә, кирәк булганда тиешле хезмәт оешмаларына бирем бирелә, аларның эше контрольгә куела.

2019 елга нәтиҗәләр ясап, аерым алганда, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен билгеләп үтәргә кирәк, төрле социаль программаларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә халыкны борчыган күп кенә актуаль темалар хәл итү юлларын табалар. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүнең иң нәтиҗәле формасы булып район Башлыгы, аның

урынбасары, Башкарма комитет җитәкчесе, аның урынбасарларының халык, студентлар, ветераннар, әниләр, гаиләләр, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре, укытучылар белән очрашулары тора. Бу очрашулар законнардагы яңалыклар турында аңлату эшләре алып барырга, федераль, республика һәм район программаларының үтәлеше турында мәгълүмат җиткерергә, район хезмәтләре һәм гомумән район җитәкчелеге эше турында тәкъдимнәр һәм искәрмәләр алырга мөмкинлек бирә. Район халкы күтәргән мәсьәләләр муниципаль район Советы, Башкарма комитет эшенең перспектив һәм агымдагы планнарында чагылыш таба, аппарат киңәшмәләрендә даими рәвештә фикер алышына. Гражданнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә катнашуларын тәэмин итү һәм катнашу өчен норматив хокукый актлар проектларын карау буенча ачык тыңлаулар үткәрелә.

Совет һәм Башкарма комитет тарафыннан, алга таба да, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карауның нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күреләчәк, гражданнарның конституцион хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча белгечләрнең җаваплылыгын күтәрүгә юнәлдерелгән эзлекле эш алып барылачак.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитетының
гомуми бүлек башлыгы

Л.Г.Хәйдәрова